ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) утыз беренче абзацта “каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю)” сүзләрен “каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аларны аерым туплау)” сүзләренә алмаштырырга;

2) утыз икенче абзацта “эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларның” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) утыз өченче абзацта “җыю (шул исәптән аерым җыю)” сүзләрен “туплау (шул исәптән аерым туплау)” сүзләренә алмаштырырга;

4) утыз алтынчы абзацта “җыюны һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июль
№ 51-ТРЗ